# «Батырлар урыны Әфганистан»

**(Багышлана Гыйлметдинов Марсель Рәшит улына Балтач районы Югары Шубан авылында яши)**

Безнең Югары Шубан авылыннан да Әфган җирләрендә сугыш утын кичеп туган якларына исән - имин әйләнеп кайткан егетләр бар.

Гыйлметдинов Марсель Рәшит улы 1966 елның 5 январендә Балтач районы Югары Шубан авылында туа, туган мәктәбебездә башлангыч белем ала, укуын Карадуган мәктәбендә дәвам итә. 1983 елда мәктәпне тәмамлый. Бабам Рәшит һәм әбием Зөлхәбирә гаиләсендә Марсель абый өченче бала. Аңа да Әфган ачысын татырга туры килгән.

Марсель абыйны Казанда Хәрби коммисариат укыта һәм ул 1984 елның 4 маенда Армия сафларына алына. Төрекмәнстанның Ашхабад шәһәрендә хәрби өйрәнүләрдә була һәм октябрь аенда Әфганстанга хәрби хезмәткә җибәрелә.

Ачлык, үзәкләргә үтә торган ачы коры җилләр, аунап яткан мәетләр, упкынга төшеп очкан машиналар, бәхетле гомер өмет итүче бичара кышлак халкы, кан - яшь, яшәү өчен көрәшкән кораллы 18-19 яшьлек Совет солдатлары. Сугышта булган мондый куркыныч күренешләрне без кинолардан гына карап беләбез. Ә кыю йөрәкле, илебез өчен көрәшкән батыр егетләребез бу вакытта нинди кичерешләр кичергәннәрдер, билгесез. Күпләр бу мәшхәрне күтәрә алмый авыруга сабыша һәм канлы вакыйгалар гомер буе күз алларыннан китми.

Марсель абый механик - йөртүче булып хезмәт итә. Бу канкойгыч сугыш турында ул бик сөйләргә яратмый, исән - сау әйләнеп кайтуына сөенеп, күтәренке күңел белән яшәргә тырыша. Бары тик землянкаларда 6 шар сәгать поста торганнарын гына әйтеп ала. Сугыш шат күңелле шаян шук Марсель абыйны, аз сүзле, җитти кешегә әверелдерә.

Безнең барыбызның да теләк бер - Җир йөзендә сугыш утлары кабынмасын. Яшь егетләрнең гомере вакытсыз өзелмәсен, ата - аналар кайгы яше түкмәсен иде. Солдат сугышны үзе сайламый, ул сугышны игълан итми. Фәкать кушылган боерыкны үти.

Марсель абыйны бәхете ташламаган: 2 ел хезмәт итеп 1986 елның 3 маенда исән-имин туган авылына кайта. Хәрби хезмәттәге вазыйфасы һәм хәрби исеме: сержант. «Сугышчы интернационалист» исемле күкрәк билгесе һәм «70 ел ВС СССР», «Изге афган сугышында катнашканы» өчен медалләре белән бүләкләнә.

1992 елда Түнтәр авылы кызы Миләүшә белән танышып тормыш корып җибәрәләр. Марсель абыйның гаиләсе бер улы, игез кызлары бар. Хәзерге вакытта

кызлары икесе дә гаиләле бәби үстерәләр. Марсель абый оныкларын бик ярата һәм аларның гаиләсе балаларына, оныкларына үрнәк булып бик матур тату гомер итә.

Эшләде: Гыйлметдинова Энҗе
Айрат кызы (14 яшь)
Шубан төп гомуми белем мәктәбе
8 нче сыйныф укучысы.
Югары Шубан авылы



